ШИМБӘ
30 МАРТ
1940 ел
№ 74 (5874)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

КОНТРОЛЬЛЕК ИТҮНЕҢ БОЛЬШЕВИСТИК СТИЛЕН ҮЗЛӘШТЕРҮ ӨЧЕН

ВКП(б) ның XVIII нче съезды производство типындагы башлангыч партоешмаларга предприятие администрациясенең эшенә контроль ясау хокукын бирде. Шуның белән съезд, завод-фабрика, совхоз-колхоз һәм МТС партоешмаларының җаваплылыгын тагын да күтәрде.

Партия оешмаларының күбесе бу мәсьәләдә—предприятие администрациясенең эшенә контроль ясау мәсьәләсендә съезд тарафыннан куелган бурычларны дөрес аңладылар һәм аны уңышлы рәвештә тормышка ашыралар. Мисаль өчен Казан шәһәрендәге 2 нче тегү фабрикасы партоешмасын (партбюро секретаре иптәш Ярин) күрсәтергә мөмкин. Производствода эшләрнең торышы турында партия җыелышларында, бюро утырышларында фабрика җитәкчеләренең докладлары тыңлана. Һәм чыгарган карарлар кичекмәстән эшчеләргә, инженер-техник работникларга җиткереләләр. Шулай итеп бөтен коллективның игтибары карарны үтәүгә юнәлдерелә. Фабрикада узган елны план арттырылып үтәлүгә дә карамастан, продукциянең сыйфаты түбән иде. 1940 нчы ел башында партия җыелышында бу турыда фабриканың техник директоры иптәш Виселевның доклады тыңлана. Шуннан соң бу карарны эшчеләргә аңлату буенча цехларда беседалар үткәрелә. Приемщиклар өчен курс оештырыла. Көндәлек эшкә техник контрольне көчәйтү белән бергә, техник директор җитәкчелегендә мастерлар катнашы белән һәр биш көн саен продукциянең сыйфатын тикшерү үткәрелә. Шушы чаралар нәтиҗәсендә продукциянең сыйфаты көннән-көн яхшыра һәм брак кими бара.

Колхозлардагы күп кенә башлангыч партоешмалар да производствога контрольлек итү буенча күренерлек уңышларга ирештеләр. Калинин районы „Удар" колхозы янындагы башлангыч партоешма колхозның хуҗалык мәсьәләләре белән тирәнтен шөгыльләнә. Оешмадагы 7 коммунистның 4 се турыдан-туры производствода эшли. Партоешма янында 18 кешедән торган агитколлектив бар. Партия һәм хөкүмәт карарларын аңлату буенча агитаторлар системалы рәвештә колхозчылар белән беседалар, җыелышлар үткәрәләр. Бригадалар белән бригадалар арасында социалистик ярыш договорлары төзелгән. Аларның үтәлеше һәр вакыт бригада стена газеталарында яктыртылып барыла. Колхозның хуҗалык мәсьәләләре белән партоешманың яхшы шөгыльләнүе һәм коммунистларның авангардлык рольләрен тәэмин итүе нәтиҗәсендә, „Удар" колхозы узган елны дәүләт йөкләмәләрен вактында һәм тулысынча үтәде. Быел язгы чәчүгә хәзерлек буенча районда алдынгы колхозларның берсе булып санала.

Администрация эшенә контроль ясауның большевистик стилен үзләштергән мондый партоешмалар безнең республикабызда аз түгел. Узган елны күпчелек предприятиеләрнең производство заданиеләрен үтәүләрендә бу бик ачык чагылды. Ләкин шуның белән бергә производствога контрольлек итү мәсьәләсендә предприятие, совхоз, колхоз һәм МТС җитәкчеләренең докладларын тыңлаудан күп ерак китә алмаган партоешмалар да бар әле.

„Урак һәм чүкеч" заводы янындагы башлангыч партоешманың (бюро секретаре иптәш Хомяков) эш стиле моңа ачык мисаль була ала. Бу оешма завод директорының докладын партия җыелышында шушы елның үткән айлары эчендә генә дә ике тапкыр тыңлаган. Шулай ук партбюро утырышында аерым цех начальникларының да докладлары тыңланган. Ләкин заводның производство тормышында бер нинди дә үзгәреш сизелми. Завод һаман да планын үтәми. Моның сәбәбе нәрсәдә соң? Моның сәбәбе завод партоешмасының производство мәсьәләсе белән җидди рәвештә шөгыльләнмәвендә, контрольлек итү эшен формаль төстә генә аңлавында. Производство алдында торган бурычларны үтәү өчен партия, профсоюз, комсомол оешмаларының бердәм рәвештә көрәшмәүләрендә.

Казан тимер юлындагы күп кенә партоешмалар, Әгерҗе районының „Кызыл Наҗар" колхозы янындагы оешма кебек башка кайбер партоешмалар да производствога контрольлек итү мәсьәләсендә үзләренең бурычларын начар үтиләр. Бу фактлар башлангыч партоешмалар алдына производствога контрольлек итү эшен тамырыннан яхшырту бурычын куялар һәм бу эштә аларга ВКП(б) райкомнары тарафыннан эшлекле ярдәм таләп ителә. Ләкин дөресен әйтергә кирәк: моңарчы бу мәсьәләдә башлангыч партоешмаларга ВКП(б) райкомнарының да, Казан Шәһәр Комитетының да ярдәме җитәрлек булмады. Без аны партиянең күптән түгел булып үткән район, шәһәр һәм өлкә конференцияләрендә делегатларның чыгышларыннан ачык күрдек.

Республикабызда гаять зур бәйрәмгә—орденлы Татарстанның XX еллыгына хәзерлек эшләре бара. Күп кенә предприятиеләрдә, совхозларда, колхозларда һәм МТС ларда бу бәйрәмне лаеклы рәвештә каршылау өчен социалистик ярыш һәм стахановчылык хәрәкәте көннән-көн җәелә. Завод-фабрикалар янындагы башлангыч партоешмаларның төп игтибары производствога контрольлек итү эшен көчәйтүгә һәм стахановчылык хәрәкәтенең яңа формасы булган күп станокчылар сафын арттыруга юнәлдерелергә тиеш. Авыл партоешмалары язгы чәчү эшләрен иң кыска срокта үткәрүне тулы тәэмин итү өчен көрәшергә һәм колхозларда ефремовчы звенолар төзүгә якыннан торып булышлык күрсәтергә тиешләр. Болар, съезд тарафыннан өченче бишьеллыкта илебез алдына куелган бурычларны уңышлы хәл итүдә ныклы этәргеч булырлар һәм орденлы республикабызның данлыклы XX еллыгын лаеклы рәвештә каршылауны тәэмин итәрләр.

СОҢГЫ СӘГАТТӘ

АНГЛИЯ—ФРАНЦИЯНЕҢ ВЕРХОВНЫЙ ХӘРБИ СОВЕТЫ УТЫРЫШЫ

ЛОНДОН, 29 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, кичә Лондонда Англия—Францияләрнең верховный хәрби советының 6 нчы утырышы булган. Франция ягыннан баш министр Рейно, диңгез министре Кампинки, авиация министре Лоран Эйнак, Франциянең Лондондагы илчесе Корбэн Леже, генерал Гамелен, адмирал Дарлан, генерал Вийемен һәм генерал Кельц, ә Англия ягыннан—баш министр Чемберлен, чит ил эшләре министре Галифакс, диңгез министре Черчилль, сугыш министре Стэнли, авиация министре Вуд, чит ил эшләре министреның урынбасары Кадоган, авиация маршалы Ньюолл, адмирал Паунд һәм генерал Айронсайд катнашканнар.

Совет утырышыннан соң игълан ителгән белдерүдә: „Верховный хәрби совет советның соңгы утырышыннан соң стратегик хәлдә булган үзгәрешләрне карады һәм алдагы хәрәкәтләр турында карарлар кабул итте" диелгән. Белдерүдә, үткән елның декабрендә Англиянең финанс министре Саймон һәм Франциянең финанс министре Рейно тарафыннан кул куелган килешүнең ил һәм империяләр ресурсларын кулланмага карата торган барлык тармакларда кулланылачагы күрсәтелә. Аннары белдерүдә болай диелә: „Франция республикасы хөкүмәте һәм Англия хөкүмәте хәзерге сугыш дәвамында үзара ризалыктан башка сөйләшүләр алып бармау, килешү яки солых договоры төзәмәү турында үзара килешүгә килделәр".

Венгриянең баш министреның Римнан китүе

ЛОНДОН, 29 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгының Римдәге хәбәрчесенең хәбәр итүенә караганда, кичә кич белән Венгриянең баш министре Телеки Римнан Будапештка киткән. Аны озатучылар арасында Италиянең чит ил эшләре министре Чиано да булган.



Советлар Союзы Герое өлкән лейтенант Л. И. Пузанов.

Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләрендә СССР Верховный Советына сайланган депутатларның исемлеге

СОЮЗ СОВЕТЫНА САЙЛАНГАН ДЕПУТАТЛАР:

УКРАИНА ССР

Волынск өлкәсе

Васюта Михаил Адамович—Ковель округы
Яковюк Мария Николаевна—Луцк округы
Чорниец Леонид Романович—Камень-Каширск округы
Дружук Мария Даниловна—Владимир-Волынск округы

Дрогобыч өлкәсе

Леженко Данило Дмитриевич—Добромиль округы
Стахурска Мелания Петровна—Самбор округы
Ткач Яков Никитович—Дрогобыч округы
Щепаник Иван Павлович—Борислав округы

Львов өлкәсе

Перепелица Мария Алексеевна—Рава-Русская округы
Василевская Ванда Львовна—Львов шәһәр округы
Студинский Кирилл Осипович—Львов округы
Грищук Леонид Стефанович—Городок округы
Садовой Василий Григорьевич—Золочев округы
Панчишин Марьян Иванович—Броды округы

Ровно өлкәсе

Сафонов Николай Антонович—Сарны округы
Гриб Яков Саввич—Костополь округы
Ефимчук-Дьячук Ульяна Васильевна—Ровно округы
Иегма Василий Андреевич—Дубно округы

Станислав өлкәсе

Владыка Анна Петровна—Станислав округы
Семанишин Николай Васильевич—Долина округы
Гуленко Михаил Васильевич—Коломыя округы
Годованец Василий Игнатьевич—Надворная округы

Тарнополь өлкәсе

Слонь Михаил Варнавевич—Кременец округы
Гречуха Михаил Сергеевич—Бережаны округы
Крих Юрий Дмитриевич—Тарнополь округы
Вовк Антон Андреевич—Чертков округы
Бабецкая Евдокия Федоровна—Бучач округы

БЕЛОРУССИЯ ССР

Белосток өлкәсе

Ковалев Михаил Прокофьевич—Белосток округы
Дьячук Мария Ивановна—Бельск округы
Игаев Семен Степанович—Ломжа округы
Пестрак Филипп Семенович—Гродно округы
Севко Павел Антонович—Волковыск округы

Брест өлкәсе

Савчук Дмитрий Иванович—Брест округы
Юхимук Софья Нестровна—Кобрин округы

Пинск өлкәсе

Приступа Андрей Иванович—Дрогичин округы
Колодич Николай Николаевич—Пинск округы

Барановичи өлкәсе

Пономаренко Пантелеймон Кондратьевич—Барановичи округы
Сержант Рафаил Иванович—Лида округы
Скобля Зоя Константиновна—Новогрудок округы
Тур Иван Петрович—Столбцы округы

Вилейка өлкәсе

Стома Василий Семенович—Вилейка округы
Богданов Иван Александрович—Поставы округы
Киселев Кузьма Венедиктович—Глубокое округы

МИЛЛӘТЛӘР СОВЕТЫНА САЙЛАНГАН ДЕПУТАТЛАР:

УКРАИНА ССР

Таценко Петр Ильич—Волынск округы
Кравчук Иван Юрьевич—Дрогобыч округы
Козырев Николай Владимирович—Львов округы
Щербак Филипп Кузьмич—Ровно округы
Гавришук Григорий Васильевич—Станислав округы
Компаниец Иван Данилович—Тарнополь округы

БЕЛОРУССИЯ ССР

Турлейский Иван Антонович—Белосток округы
Притыцкий Сергей Осипович—Гродно округы
Черник Мария Николаевна—Барановичи округы
Патеруха Степан Филиппович—Брест округы
Клевец Антон Степанович—Пинск округы
Малевич Антон Семенович—Вилейка округы

КАЗАН РАДИОКОМИТЕТЫ РАБОТНИКЛАРЫ КОЛЛЕКТИВЫНА

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты Казан шәһәренең радиокомитеты работниклары коллективын Совет радиосының данлыклы 15 еллыгы белән кайнар рәвештә котлый.

Маркс—Энгельс—Ленин—Сталинның бөек идеяләрен пропагандалауның куәтле средствосы булган радио, хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләү коралы.

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты радио работникларының киләчәктә дә марксизм-ленинизм нигезләрен үзләштереп, тапшырыла торган материалларның сыйфатын яхшыртып, ВКП(б) ның XVIII нче съездының тарихи карарларын үтәү өчен, илебездә коммунизмның тантанасы өчен көрәшәчәкләренә нык ышана.

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты.

ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

ШӘРИФ КАМАЛГА (Байгильдиевка) Татарстан АССР ның атказанган сәнгать эшлеклесе исмен бирү турында

Татар әдәбиятын һәм сәнгатен үстерү эшендә күренекле хезмәтләре өчен, әдәби һәм җәмагать эшенең 30 еллык юбилее уңае белән, Шәриф Камалга (Байгильдиевка) Татарстан АССР ның атказанган сәнгать эшлеклесе исмен бирергә.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Г. ДИНМӨХӘМЕТОВ.
Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Секретаре М. ЯКУПОВ.

Казан, Кремль.
26 март, 1940 ел.

ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Мәрьям Фәхерттин кызы ГАЙНЕТТИНОВА иптәшне Татарстан АССР ның Социаль Тәэминат Халык Комиссары итеп билгеләү турында

Мәрьям Фәхерттин кызы Гайнеттинова иптәшне Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының Социаль Тәэминат Халык Комиссары итеп билгеләргә.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Г. ДИНМӨХӘМЕТОВ.
Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Секретаре М. ЯКУПОВ.

Казан, Кремль.
26 март, 1940 ел.

КОЛХОЗЛАРДА ЭШ АТЛАРЫННАН ФАЙДАЛАНУ ТУРЫНДА

(ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросында)

ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы үзенең чираттагы утырышында, Татарстан колхозларында эш атларыннан файдалану һәм аларны тәрбияләү мәсьәләсен тикшерде. Тикшерү нәтиҗәләреннән чыгып бюро утырышы түбәндәгеләрне күрсәтеп үтте:

Күп кенә районнарда эш атлары кирәкле сбруйлар белән һәм транспорт белән кирәгенчә тәэмин ителмәгәннәр. Бу эш Лаеш районында аеруча начар тора. Лаеш районында шушы елның 1 нче январена районда булган 3.949 эш атына бары тик 1.560 арба, 1.969 чана, 2.580 камыт бар иде. Ә инде „Яңа алан" кебек аерым колхозларда бу эшнең торышы тагын да начарырак, бу колхозда булган 100 баш эш атына бары тик 60 чана, 40 арба, 58 камыт бар. Куйбышев исемендәге колхозда 46 баш атка 17 чана, 14 арба, 15 камыт бар һ. б.

ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы республиканың аерым колхозларында яшәп килә торган мондый хәлгә түзеп торырга мөмкин булмаган күренеш дип бәя бирде һәм партиянең район оешмаларын, хезмәт ияләре депутатларының район советлары башкарма комитетларын һәм район җир бүлекләрен колхозларда эш атларын транспорт кирәк-яраклары белән тәэмин итү өлкәсендәге мондый җитешсезлекләрне бик тизлек белән бетерергә мәҗбүр итте.

Күп кенә районнарда эш атларын тәрбияләү мәсьәләсе дә мактарлык тормый. Мәсәлән, Тельман районы буенча тикшерелгән 2.577 баш атның бары 32 башы гына яхшы көрлектә, ә 214 баш ат уртача көрлектә, 891 баш ат уртачадан түбән көрлектә һәм 1.438 баш атның ябык хәлдә булуы беленде. Лаеш районында тикшерелгән 1.757 баш атның 883 башы ябык хәлдә булуы беленде һ. б.

ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы колхозларда эш атларын тәрбияләүнең торышы канәгатьләнмәслек булуын күрсәтте һәм бу эшне яхшырту буенча күп кенә практик чаралар билгеләде. ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы карары буенча ТАССР Наркомземы, район җир бүлекләре, МТС лар, район советларының башкарма комитетлары һәм ВКП(б) райкомнары түбәндәге чараларны үткәрергә тиешләр:

Барлык колхозларда сбруйларга һәм транспортка ремонт ясау өчен ремонт бригадалары оештырылырга, эш атлары өчен кирәк булган барлык сбруйларга һәм транспортка ремонт ясалырга һәм алар эш атларына беркетелергә тиешләр. Шул ук вакытта үзләренә беркетелгән атлар белән эшләүче колхозчылар квартираларында ат сбруйларын саклау кебек күренешләргә һич тә юл куелмаска тиеш.

Барлык колхозларда шушы елның 10 нчы апреленнән дә соңга калмыйча ат караучылар бригадалары төзелергә, алар тикшерелгән кешеләр белән тулысынча тәэмин ителергә, бу бригадаларга атлар беркетелергә һәм ат караучыларга хезмәт хакы түләү эше колхозларда атларны тәрбияләү турындагы инструкция нигезендә алып барылырга тиеш.

Авыл хуҗалыгы эшләрендә җанлы тарту көчләреннән тулы файдалану буенча һәрбер колхозда ныклы план төзелергә һәм анда трактор эшләре тулы рәвештә исәпкә алынырга тиеш.

ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы атларның торышы өчен җаваплылыкны, шулай ук колхозларда чаптыру кампаниясен үткәрүдә, яш атларны һәм колыннарны саклауда җаваплылыкны бригадаларда бригадирга, ә тулай колхоз күләмендә правление председателенең үзенә йөкләтелгәнлекне аеруча күрсәтеп үтте. Барлык колхозларда, эш киеренке булган вакытларда да, эш атларына атна саен ял бирелергә тиеш.

Район советларының башкарма комитетлары, район җир бүлекләре һәм МТС лар, 10 көн срок эчендә, колхозлар катнашы белән, ат сбруйларының һәм транспортның торышын тикшерергә, язгы чәчү вактына колхозларның сбруйлар һәм транспорт белән тулысынча тәэмин ителүләренә ирешергә тиешләр. Шулай ук ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы Татарстан Совнаркомына үзенең 1939 нчы елның 9 нчы декабрьдә чыгарган карарының үтәлешен тикшерүне тапшырды. Район советларының башкарма комитетлары, район җир бүлекләре һәм МТС лар леспромхозларга, кустарь-промысло артельләренә сбруйлар һәм транспорт кирәк-яраклары эшләү өчен колхозлардан эш көчләре бирергә тәкъдим итте.

Консультация

СОВЕТЛАР СОЮЗЫНЫҢ ТӨП ЭКОНОМИК БУРЫЧЫ

Тарих күзлегеннән караганда кыска гына вакыт эчендә Советлар Союзы чиксез зур уңышларга иреште. Сталинчыл икенче бишьеллыкның уңышлы үтәлүе нәтиҗәсендә икенче бишьеллыкның төп тарихи бурычы хәл ителде—барлык эксплоататор сыйныфлар тәмам бетерелделәр, кешенең кешене эксплоатацияләвен тудыра торган сәбәпләр тулысынча юк ителделәр. Социалистик революциянең иң кыен бурычы хәл ителде: авыл хуҗалыгын коллективлаштыру тәмамланды, колхоз строе тәмам ныгыды. Безнең илебездә коммунизмның беренче фазасы—социализм нигездә тормышка ашырылды. Без өченче бишьеллыкның үсешен яңа полосасына—сыйныфсыз социалистик җәмгыять төзүне тәмамлау һәм социализмнан коммунизмга тезмәле рәвештә күчү полосасына кердек.

Промышленностебызның үсеш темплары буенча һәм производство техникасы буенча без төп капиталистик илләрне куып җиттек һәм узып киттек. Үзенең үсеш темплары буенча безнең социалистик промышленностебыз дөньяда беренче урында тора. Сугышка кадәр дәрәҗә белән чагыштырганда безнең промышленностебыз 9 тапкыр үсте. Ә шул ук вакыт эчендә төп капиталистик илләрнең промышленносте бары 20—30 процентка гына үсте. Димәк, социалистик промышленностьның үсеше гаять кызу темплар белән бара. Ләкин без экономик яктан, ягни промышленность производствосының җан башына туры килә торган күләме ягыннан төп капиталистик илләрдән һаман да артта барабыз әле.

Партиябезнең тарихи XVIII нче съезды безнең һәм хезмәт ияләренең бөек юлбашчысы иптәш Сталин ил алдына гаять зур һәм җаваплы бурыч куйдылар—Советлар Союзы Европаның иң алга киткән капиталистик илләрен һәм Америка Кушма Штатларын экономик яктан якын 10—15 ел эчендә куып җитәргә һәм узып китәргә тиеш. „Производство техникасы һәм промышленностьның үсеш темплары ягыннан без төп капиталистик илләрне узып киттек. Бу бик яхшы. Ләкин бу аз. Аларны шулай ук экономик яктан да узып китәргә кирәк. Без моны эшли алабыз, һәм без моны эшләргә тиешбез." (Сталин). Юлбашчы тарафыннан куелган бу зур һәм җаваплы бурычны үтәү өчен бездә барлык мөмкинлекләр дә бар.

Советлар Союзының хәзерге вакытта капиталистик илләрдән экономик яктан артта калуының төп сәбәбе патша Россиясенең безгә калдырган мирасыннан килүеннән гыйбарәт. Табигый байлыклары чиксез күп булган Россияне элек власть башында утырган алпавытлар һәм капиталистлар артта сөйрәделәр, хезмәт ияләрен ачлыкта яшәргә мәҗбүр иттеләр.

Мәсәлән, ташкүмер һәм соры күмер чыгаруның җан башына туры килә торган күләме Россиядә 1913 нче елны Америкага караганда 26 тапкыр, Англиягә караганда 31 тапкыр, Германиягә караганда 15 тапкыр, Франциягә караганда 5 тапкыр ким иде. Электр энергиясе җитештерүнең җан башына туры килә торган күләме Россиядә 1913 нче елны Америкага караганда 17 тапкыр, Германиягә караганда 5 тапкыр ким иде. Чуен коюның җан башына туры килә торган күләме шул ук 1913 нче елны Россиядә Америкага караганда 11 тапкыр, Англиягә һәм Германиягә караганда 8 тапкыр, Франциягә караганда 4 тапкыр ким иде. Корыч коюның җан башына туры килә торган күләме 1913 нче елны Россиядә Америкага караганда 11 тапкыр, Германиягә караганда 8 тапкыр, Англиягә караганда 6 тапкыр, Франциягә караганда 4 тапкыр ким иде.

Власть башында алпавытлар һәм капиталистлар утырган патша Россиясе алга киткән капиталистик илләрне куып җитә алмады гына түгел, бәлки торган саен алардан артта кала барды. Мәсәлән, чуен җитештерүнең җан башына туры килә торган күләме Россиядә 1900 нче елны АКШ ка караганда 8 тапкыр ким булган булса, 1913 нче елны инде 11 тапкыр ким булды. Германия белән чагыштырганда Россиядә чуен җитештерү 1900 нче елны 6 тапкыр чамасы түбән булса, 1913 нче елны инде 8 тапкыр түбән тора. Җир шарының алтыдан бер өлешен биләгән, халкының күплеге ягыннан дөньяда өченче урында торган элекке Россия промышленность производствосының күләме ягыннан дөньяда бишенче, Европада дүртенче урынны гына алып тора иде. 1913 нче елны бөтен дөнья күләмендәге промышленность продукциясенең бары 2,6 проценты гына Россия өлешенә төшә иде. Ә АКШ өлешенә бөтен дөнья күләмендәге промышленность продукциясенең 38,2 проценты, Англиягә 12,1 проценты, Германиягә 15,3 проценты, Франциягә 6,6 проценты туры килә иде. Бу саннар үзләре генә дә элеккеге Россиянең экономик яктан никадәр артта калганлыгын ачык күрсәтәләр.

Промышленностьның автомобиль, трактор, ясалма ефәк, алюмин, самолет җитештерү кебек бик мөһим тармаклары элекке Россиядә бөтенләй юк иде. Промышленностьның башка күп кенә тармаклары да кызганыч хәлдә артта калып баралар иде.

Дүрт ел дәвам иткән империалистик сугыш, 3 ел буена барган гражданнар сугышы нәтиҗәсендә элек тә артта барган Россия тагын да артка чигенде, халык хуҗалыгы чыгырыннан чыкты. 1920 нче елны промышленность продукциясе сугышка кадәр булганның бары 20 процентын гына тәшкил итә иде.

Димәк, яшь Совет власте алдында халык хуҗалыгын аякка бастыру буенча гаять зур бурычлар тора иде. 1925—26 нчы елларда безнең промышленностебыз инде сугышка кадәре булган күләменә җиткерелде. 1926 нчы елдан алып 1938 нче елга кадәре булган 12—13 ел эчендә социалистик промышленность 9 тапкырдан артык үсте. Мондый үсешнең тарихта тиңдәше булмаган кызу үсеш икәнен тагын да ачыграк күз алдына китерү өчен капиталистик илләрнең үсеше белән чагыштырып карыйк.

Капиталистик илләрнең барсын бергә алганда промышленность продукциясенең 8—9 тапкыр үсеше өчен 1850 нче елдан алып 1929 нчы елга кадәр булган 80 ел вакыт кирәк булды.

Безнең промышленностьның үсеш темпы АКШ белән чагыштырганда 7,5 тапкыр, Англия белән чагыштырганда 8 тапкыр, Германия белән чагыштырганда 7 тапкыр тизрәк булды. Шуның нәтиҗәсендә безнең социалистик промышленностебыз экономик яктан алга киткән капиталистик илләрне куып җитүдә зур адымнар атлады. Бу хәл беренче һәм икенче бишьеллык планнарның уңышлы үтәлүе нәтиҗәсендә тагын да ачык күренде. Мәсәлән, җан башына туры килә торган промышленность продукциясе буенча 1913 нче елда Россия Америка Кушма Штатларыннан 21 тапкыр артта калып барган булса, хәзер инде Советлар Союзы АКШ тан 3 тапкыр гына артта калып бара. Шул ук 1913 нче елны Россия Германиядән 13 тапкыр артта бара иде, хәзер без 2 тапкыр гына артта калып барабыз. Англиядән 1913 нче елны Россия 14 тапкыр артта калып бара иде, хәзер без 2 тапкырга гына артта калып барабыз. Франция Россиядән 8 тапкыр алда бара иде, ә без хәзер Францияне куып җиттек.

Бу фактлар барсы да—социалистик системаның капиталистик системадан чиксез өстенлеге турында, безнең уңышларыбызның тарихта тиңдәше булмаган зур уңышлар икәнлеге турында сөйлиләр.

Ләкин, без хәзерге вакытта алдынгы капиталистик илләрдән экономик яктан, бигрәк тә электр энергиясе, чуен, корыч, ташкүмер, цемент җитештерүнең җан башына туры килә торган күләме ягыннан артта калып барабыз әле. 1938 нче елны без 15 миллионга якын тонна чуен эшләп чыгардык, Англия 7 миллион тонна эшләп чыгарды. Англияне экономик яктан куып җитү өчен безгә чуен коюны елына 25 миллион тоннага җиткерергә кирәк. Чөнки бездә халык саны Англиягә караганда 4 тапкыр чамасы артыграк. 1938 нче елны 18 миллион тонна чуен эшләп чыгарган Германияне экономик яктан узып китү өчен безгә чуен эшләп чыгаруны елына 40—45 миллион тоннага җиткерергә кирәк. Чөнки бездә халык саны Германиягә караганда 2 тапкырдан күбрәк. 1929 нчы елны 43 миллион тонна чуен эшләп чыгарган АКШ ны экономик яктан узып китү өчен безгә һәр елны 50—60 миллион тонна чуен җитештерергә кирәк. Чөнки Советлар Союзында халык саны АКШ тагы халык санына караганда шактый артык.

Ләкин, экономик ярышта Советлар Союзы капиталистик илләрне, һич шиксез, куып җитәчәк һәм узып китәчәк. Моның өчен бездә бөтен мөмкинлекләр бар. Иң элек—Советлар Союзы дөньяда иң алдынгы җәмгыять строенаия булып тора. Советлар Союзында бер-берсенә каршы булган, антогонистик сыйныфлар юк, безнең җәмгыятебез бер-берсенә дус булган ике сыйныфтан—эшчеләр сыйныфыннан, крестьяннәр сыйныфыннан һәм социалистик интеллигенциядән тора. Аннан соң, Советлар Союзы табигать ресурсларына — тимер рудасына, нефтькә, су энергиясенә, марганс рудасына, алтынга, плотинага һәм башка бик күп төрле кыйммәтле металларга булган запас байлыгы буенча дөньяда беренче урында тора. Социализм хуҗалыгының гаять тиз үсеше, ватаныбызның чәчәк атуы өчен кирәк булган барлык ресурслар безнең илебездә бар.

Һәрбер җәмгыяттә, аның экономик яктан алга китүе өчен хезмәтнең җитештерүчәнлеге хәл иткеч урын тота. „Капитализм ни өчен феодализмны җимерде һәм җиңеп чыкты? Чөнки ул хезмәтнең җитештерүчәнлегенең югарырак нормаларын тудырды, ул, җәмгыяткә продуктларны, феодализм тәртипләре вактында булганга караганда, чагыштырмаслык дәрәҗәдә күбрәк алырга мөмкинлек бирде. Чөнки ул җәмгыятьне баерак итте. Социализм ни өчен капиталистик хуҗалык системасын җиңә ала, җиңәргә тиеш һәм әлбәттә җиңәчәк? Чөнки, ул, капиталистик хуҗалык системасына караганда, хезмәтнең югарырак үрнәкләрен, хезмәтнең югарырак җитештерүчәнлеген бирә ала. Чөнки ул җәмгыяткә продуктларны күбрәк бирә ала һәм җәмгыятьне, капиталистик хуҗалык системасына караганда, баерак итә ала" (Сталин).

Хезмәтнең җитештерүчәнлеген күтәрү буенча социалистик хуҗалык системасының капиталистик хуҗалыктан чагыштыргысыз рәвештә алда торганын күрәбез. 1929 нчы елдан 1937 нче елга кадәр булган вакыт эчендә капиталистик илләрдә хезмәтнең җитештерүчәнлеге бары 4 процентка гына үсте, ә аерым илләрдә, мәсәлән, Франциядә, артмады гына түгел, хәтта кимеде. Безнең илдә, хезмәтнең җитештерүчәнлеге һәр вакыт туктаусыз алга бара. Сталинчыл беренче бишьеллыкта промышленностьта хезмәтнең җитештерүчәнлеге 41 процентка, икенче бишьеллыкта 82 процентка үсте. Өченче бишьеллыкта 65 процентка үсәргә тиеш. Хезмәт җитештерүчәнлегенең һәр проценты ватаныбызның байлыгын арттыруда чиксез зур урын тота. Илнең байлыгы үскән саен бу процентның әһәмиятләлеге дә арта бара. Мәсәлән, беренче бишьеллыкта һәрбер процент елга 310 миллион сум биргән булса, икенче бишьеллыкта ул 500 миллион сумга күтәрелде, ә өченче бишьеллыкта һәрбер процент 1 миллиард сум бирергә тиеш. Әгәр дә икенче бишьеллыкта промышленность үсешенең 60 проценты хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү исәбенә үскән булса, өченче бишьеллыкта промышленность үсешенең 73 проценты хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү исәбенә үсәргә тиеш.

Димәк, Советлар Союзының төп экономик бурычын хәл итүдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү хәл иткеч урынны алып тора. В. И. Лениннең „хезмәт җитештерүчәнлеге, ул, соңгы чиктә, яңа иҗтимагый стройның җиңүе өчен иң әһәмиятле, иң төп нәрсә" дигән сүзенең никадәр тирән мәгнәле, никадәре даһи күрсәтмә икәнен тормыш үзе дөресли.

Хезмәт җитештерүчәнлеге никадәр тизрәк үссә, төп экономик бурыч шул кадәр тизрәк хәл ителәчәк, капиталистик илләрне экономик яктан куып җитү һәм узып китү өчен кирәк булган вакыт та шул кадәр азрак кирәк булачак.

Партиябезнең XVIII нче съезды карарлары һәм иптәш Сталинның күрсәтмәләре белән коралланган совет халкы, съезддан соң үткән бер ел вакыт эчендә, социалистик хуҗалыкның барлык тармакларында тагын да яңа уңышларга иреште. Хезмәтнең җитештерүчәнлеген күтәрү буенча зур эшләр эшләнде. Стахановчылык хәрәкәтенең яңа формалары—күп станокчылар хәрәкәте, бер юлы берничә профессияләрне үзләштерү хәрәкәте, хезмәт җитештерүчәнлеге буенча бишьеллык планны дүрт елда үтәү өчен көрәш йөзпотчылар хәрәкәте кебек хезмәткә коммунистик мөнәсәбәтнең бик күп яңа төрләре киң колач алдылар. Болар барсы да төп экономик бурычны уңышлы хәл итүдә чиксез зур роль уйныйлар.

Г. Баязитов.

Язгы чәчү алдыннан

Орлык агулау массовый төстә бара

АКТАНЫШ, 29 март. (Телефон буенча). Районның колхозларында чәчү орлыгын термик ысул белән агулау эшләре массовый төстә бара. „Көрәш" колхозы 23 центнер, „Кызыл көч" колхозы 46 центнер, „Үрнәк" колхозы 31 центнер, „Яңа тормыш" колхозы 36 центнер һәм Ленин исемендәге колхоз 18 центнер агуладылар инде.

Быел районның колхозларында 1.800 центнер чәчү орлыгы термик ысул белән агулап чәчеләчәк. Орлык агулау эшендә 260 колхозчы эшли. Алар барсы да бу эшкә тотынганчы 3 көнлек курста укыдылар.

Шуның белән бергә районның күпчелек колхозларында бәрәңгене яровойлаштыру эшләре дә башланды. „Кызыл игенче" колхозы 30 центнер, Ленин исемендәге колхоз 60 центнер, „Радио" колхозы 48 центнер бәрәңгене яровойлаштырырга салды.

Ә. Сафин.

ӘЛМӘТ, 28 март. (Телефон буенча). Районның „Иркен юл", „Туры юл" колхозлары бодай орлыгын термик агулау эшенә керештеләр. Районда 1.000 центнердан артык бодай орлыгы термик ысул белән агулап чәчеләчәк. Шул исәптән быел ефремовча иген уңышы алуга йөкләмә алган звеноларның барлык бодай культуралары орлыгы термик ысул белән агуланачак.

Орлык агулау эшләре „Туры юл" колхозында (председателе иптәш Закиров) аеруча яхшы оештырылган. Колхозда агулау өчен кирәкле барлык инвентарьлар һәм агулау препаратлары алдан хәзерләп куелган.

Хасаншин.

Юдино районы „Яңа тормыш" колхозыннан Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә кандидатлар. Сулдан уңга—(беренче рәт)—колхоз председателе Х. Вәлиев, колхоз счетоводы П. И. Левин, сыер сауучылардан: С. Шәрәфетдинова, Ю. Я. Михайлова, кыр белгече Ш. Миңлебаев һәм ферма мөдире С. Камалов иптәшләр. И. Галиев фотосы.

КУРСНЫ УҢЫШЛЫ ТӘМАМЛАДЫЛАР

Шөгер МТС ы үткән елның декабрь аенда тракторчылар хәзерләү буенча курс оештырган иде. Курсантлар үзара ярышып укыдылар. Нәтиҗәдә 48 кеше укуны яхшы билгеләренә тәмамлап, тракторчы булу хокукы алып чыктылар. Галиева һәм Вильданова иптәшләр курсны аеруча яхшы тәмамладылар. Шушы көннәрдә хатын-кызлардан тагын 16 кеше тракторчылар хәзерләү курсын тәмамлыйлар.

С. Габитов.

ОРЛЫК БЕЛӘН КОЛХОЗАРА ЯРДӘМ

Кызыл юл районы колхозларында чәчүлек орлыгы җитмәгән колхозларга һәм күрше районнарга чәчүлек орлыгы белән ярдәм итү эше киң җәелде. Карл Маркс исемендәге колхоз Калинин исемендәге колхозга 550 центнер, күрше районнарга 305 центнер чәчүлек орлыгы бирде. Шурабаш колхозы „Көрәш" колхозына 250, күрше районга 280 центнер орлык бирде. „Яңа тормыш" колхозы членнары үзләреннән артык булган 650 центнер чәчүлек орлыгын башка район колхозларына бирергә бер тавыштан карар чыгардылар.

„Комбайн" колхозы членнары Хәким һәм Касыйм Шакиров иптәшләр чәчүлек орлыгы булмаган күрше район колхозларына ярдәм нигезендә бишәр центнер орлык бирделәр. (ТатТАСС).

МТС ларда тракторларга ремонт ясауның барышы турында Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариаты сводкасы

1940 нчы елның 25 нче мартына

(Планга карата процентларда)

МТС лар	Үтәлеш проценты	МТС лар	Үтәлеш проценты	МТС лар	Үтәлеш проценты
Нәркәй	100	Столбище	90,9	Макыл	74,5
Тымытык	100	Шөгер	90,9	Дөбъяз	74,1
Теләче	100	Норлат	89,1	Балык Бистәсе	73,7
Кама Тамагы	100	Буа	88,4	Салман	73,7
Маткавыш	100	Мәлки	87,5	Мөрәле	73,5
Актаныш	100	Дәүләки	87,5	Олы Карилә	72,9
Мөслим	100	Иске Писмән	87,0	Кошкино	72,5
Янил	100	Чыбыклы	86,5	Чиябаш	72,5
Чалпы	100	Тәтеш	86,1	Акташ	72,2
Алга	100	Этнә	86,0	Чүрибураш	72,1
Кадрәк	100	Әлки	86,0	Баулы	71,9
Тирсә	100	Морт	85,1	Зирекле	70,7
Т. Тамак	100	Мамадыш	83,3	Каргалы	70,2
Минзәлә	100	Чишмә	83,3	Үзәк	69,2
Иске Чишмә	100	Мөслим (Чистай)	83,3	Бөгелмә	69,0
Юртыш	100	Биектау	83,0	Константиновский	68,7
Азин	100	Кәкре Елга	81,8	Тат. Ялтан	64,8
Әлмәт	100	Исәнбай	81,6	Соколка	64,4
Балтач	100	Кузнечиха	81,5	Кузайкино	63,5
Беренче Май	100	Тәкәнеш	81,5	Рождественский	62,3
Сарман	100	Юдино	80,9	Тельман	62,0
Черемуховский	100	Трехозерский	80,0	Карамалы	61,2
Саба	100	Калинин	79,6	Димитровский	60,6
Кукмара	97,9	Ютазы	79,6	Яңа Чишмә	60,0
Тархан	97,7	Биләр	78,7	Поповка	59,2
Кичү	96,3	Тат. Ходяш	78,7	Чокалы	58,2
Кызыл Чапчак	96,0	Әлши	78,6	Зайнский	56,9
Чаллы	95,8	Кызыл Юл	78,0	Ромадановский	54,5
Чистай	95,0	Майдан	77,4	Зөя	41,1
Буденный	94,5	Әхмәмәт	77,3		
Ишеево	94,1	Кызыл Йолдыз	76,4	Барлыгы	82,6
Куйбышев	94,0	Базарлы Матак	75,9		
Бондюг	93,0	Иске Тимошкино	75,6	1940 нчы елның 20 нче мартына	79,7
Аксубай	92,9	Арча	75,0		
Зур Поляна	92,9	Алексеевский	75,0	1939 нчы елның 25 нче мартына	85,9
Октябрь	92,9	Питрәч	75,0		
Чүпрәле	92,7	Алабуга	74,5		

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНДА

Колхозларда техник культуралар уңышын үткәрү чаралары турында

Шушы көннәрдә ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы колхозларда техник культуралар уңышын күтәрү чаралары турындагы мәсьәләне карады. Техник культураларга урыннардагы оешмаларның һәм җир органнарының җитәкчелеге бөтенләй канәгатьләнерлек булмау нәтиҗәсендә, техник культураларның уңышы бик түбән хәлдә булуында дәвам итә. 1939 нчы елда долгунец җитеннең 47 проценты һәлак булды, ә калган участкыларда гектарыннан бары тик 0,7 центнер сүс һәм 1,3 центнер орлык алынды. Республикабызның колхозларында, МТС ларында җитен һәм киндерне эшкәртү өчен бик күп машиналар булуга карамастан, алар гафу ителмәслек дәрәҗәдә начар файдаланылалар. Мәсәлән, Балык Бистәсе районында җитен эшкәртү буенча унбер машинаның берсе дә файдаланылмады, ә Бөгелмә, Мәлки МТС ларында исә киндер эшкәртү машиналары ике елдан бирле хәрәкәтсез яткырылалар. Техник культуралар буенча махсус курсларда хәзерләнгән кадрлар күп кенә хәлләрдә урынсыз файдаланылалар. ВКП(б) Үзәк Комитетының һәм СССР Совнаркомының 1939 нчы ел, 28 нче майда кабул ителгән карарында җитенчелек һәм киндерчелек эшенең Татарстанда артта калып баруы күрсәтелгән иде. Ләкин республикабызның җир органнары, район башкарма комитетлары, ВКП(б) райкомнары ул карардан үзләре өчен тиешле нәтиҗә ясамадылар һәм техник культураларның эшен яхшырту буенча асылда практик чаралар кулланмадылар, күп кенә районнарда бу эшне үз агымына куйдылар.

Үткән елгы мондый ялгышлар быел да кайбер районнарда кабатлана, техник культураларны чәчү өчен кирәк булган мәйданны туфракның сыйфатын искә алмыйча билгеләү, техник культуралар буенча даими звенолар оештыру эшенә игтибар бирмәү фактлары бар. Шулай ук Татнаркомзем һәм аның производство-территориаль управлениесе дә техник культуралары буенча язгы чәчүгә хәзерлеккә оператив җитәкчелек итмиләр. Шуның нәтиҗәсендә күп кенә районнарда техник культуралар орлыгы туплау һәм аларны тикшерү, хәзерләү пунктларыннан алмаштырып алу эшләре канәгатьләнмәслек хәлдә тора. Мәсәлән, Кайбыч районында 536 центнер җитен орлыгының бары 186 центнеры гына тикшерелгән һәм шулардан 176 центнеры кондициясез дип табылган. Шундый ук хәл Кызыл Йолдыз һәм башка кайбер районнарда да бар.

Күп кенә районнарда партия һәм совет оешмалары, җир органнары кок-сагызга әһәмият бирмиләр.

ВКП(б) Өлкә Комитеты техник культураларга мондый карашларның кичекмәстән бетерелергә тиешлеген күрсәтеп, техник культураларның уңышын күтәрүне тәэмин итә торган күп кенә чаралар билгеләде һәм аларны үткәрүне тәэмин итү эшен Татнаркомземга, Райзо һәм МТС җитәкчеләренә, район башкарма комитетларына һәм ВКП(б) райкомнарына йөкләде. Бу чаралар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Җитенне иң яхшы җирләргә, уйсу участкыларга чәчәргә, коксагыз һәм киндерне бары тик иң уңдырышлы участкыларга гына чәчәргә һәм бу культураларны чәчү участкыларын натурада билгеләүне, сыйфатын тикшерүне, агрономнар белән берлектә, 10 нчы апрельгә тәмамларга. Бу культуралар чәчелә торган җирләрдә кар суы тоту эшен һич шиксез үткәрергә, ул участкыларның барсына да минерал һәм органик ашламалар кертергә. Бу культураларны җәй көне тәрбияләү эшен үрнәк итеп оештырырга, кимендә ике тапкыр җентекләп утарга, рәт араларын йомшартуны оештырырга. Мәк, көнбагыш, цикорийларны кимендә 2—3 тапкыр утарга, кок-сагызның рәт араларын 4—5 тапкыр йомшартырга кирәк.

Югары уңыш алу хезмәтне дөрес оештыруга бик нык бәйләнгән. Шуңа күрә район җир бүлекләре һәм МТС лар колхозларда техник культуралар игү буенча махсус звенолар оештыруга һәм ул звеноларның даими булуларына зур игтибар итәргә тиешләр. Звеноларга беркетелгән участкыда үткәрелергә тиешле агротехника чаралары буенча звеноларга комплекс план җиткерергә һәм аның үтәлүен системалы рәвештә тикшерүне оештырырга. Звено членнарының барсы да апрель аенда агротехника курслары аша үткәрелергә тиеш.

Татнаркомзем, район җир бүлекләре һәм МТС җитәкчеләре, райбашкармалар һәм ВКП(б) райкомнары техник культураларга карата үзләренең игтибарларын көчәйтергә һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының һәм СССР Совнаркомының 1939 нчы ел, 28 нче май карарында күрсәтелгән барлык чараларны тулысынча үткәрүгә ирешергә тиешләр.

Ш. Камал юбилеенә багышланган тантаналы җыелыш

Татар совет әдәбиятының күренекле вәкиле Шәриф Камалның әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлегенең 30 еллык юбилеенә багышлап, кичә, Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театрында зур тантаналы җыелыш булды.

Җыелышның президиумына көчле кул чабулар астында юбиляр Шәриф Камал, ВКП(б) Өлкә Комитеты секретарьлары Алемасов, Матвеев, Абделмәнев, Мөхәметов, Долотказин, Татарстан Совнаркомы председателе Гафиятуллин, СССР Совет Язучылары Союзы вәкилләре Павел Панченко һәм Әхмәт Фәйзи, кардәш республикаларның вәкилләре проф. Мөхәмәдиаров, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Салих Сәйдәшев, Татарстанның халык артистлары Нафига Таҗдарова, Галия Кайбицкая, Григорьев һ. б. иптәшләр сайланды.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе орденлы драматург иптәш Т. Гыйззәтнең тәкъдиме буенча җыелыш көчле алкышлар астында ВКП(б) Үзәк Комитетының иптәш Сталин җитәкчелегендәге политбюро составын һәм Димитров, Тельман иптәшләрне почетлы президиумга сайлады.

Шәриф Камалның иҗаты турында Г. Кашшаф һәм М. Җәлил иптәшләрнең докладлары булды.

Казанның уку отличниклары-пионерлар язучыга үзләре иҗад иткән самолет моделен, мехкомбинат эшчеләре иптәш Сталинның зур күләмдә мехтан ясалган портретын бүләк иттеләр. СССР Совет Язучылары Союзыннан иптәш Панченко юбилярны котлап ялкынлы речь сөйләде. Язучы адресына күп сандагы котлауларны җыелыш зур күтәренкелек белән каршылады һәм юбилярны көчле алкышлар белән кат-кат котлады.

Җыелыштан соң, Татар Дәүләт Академия театры көчләре белән Шәриф Камалның төрле пьесаларыннан аерым пәрдәләр һәм картиналар уйналды. Аннан соң булган концертта Татар Дәүләт Опера театрының күренекле көчләре һәм шагыйрьләрнең чыгышлары булды.

Совет радиотапшыруының 15 еллыгы

Үткән 15 ел эчендә Совет радиотапшыруы киң колач алды.

СССР да радиотапшыруның үсүе белән бергә, безнең Татарстан республикасында да радиотапшыру үсте. Казанда 10 киловатт көчле радиостанция салынды. Хәзер республикада чыбык буйлап тапшыручы 130 радиоузел эшли. Репродукторлар саны 42.000 нән арта. Лампалы приемниклар 6.000 нән артык санала. Үзәк, республика тапшыруларын һәм җирле тапшыруларның көн саен ярты миллионга якын кеше тыңлый. Үткән елны республика Элемтә бүлеге Зеленодольски, Чепья, Олы Тархан, Балык Бистәсе, Буа һ. б. урыннардагы радиоузелларны яңа баштан үзгәртеп корды. Май аена Кыят, Галактионов, „КИМ" совхозларында радиоузеллар эшли башлачак.

Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлау кампаниясе вакытында радио гаять зур эш үткәрде. Радио масса арасында агитация алып баруның иң әһәмиятле средстволарыннан берсе булып эверелде, ул йөз меңнәрчә агитаторларның һәм пропагандистларның эшендә актив ярдәмче булды.

Радиокомитет һәм районнардагы радиотапшыру редакцияләре республика һәм район тормышын тирәнтен һәм һәр яклап күрсәтергә тиешләр. Ләкин радио работниклары әле бу эшне канәгатьләнерлек алып бармыйлар. Тапшыру эшендә оперативлык җитешми. Мәсәлән, Минзәлә, Буденный радиоузелларында „Соңгы хәбәрләр" аена 2—3 тапкыр гына тапшырыла.

Политик, музыкаль һәм әдәби-драматургик тапшыруларны планлаштыру күбесенчә масса катнашыннан башка үткәрелә. Кай вакытларда үзәк радиодан концерт тапшырылганнан соң өлкә радиосы да шул темага, ләкин начаррак сыйфатлы концерт тапшыра. Билгеле, мондый концертлар радио тыңлаучыларны канәгатьләндермиләр.

Радиотапшыру редакцияләре тапшыру планнарын актив белән, партия, совет, комсомол работниклары белән, промышленностьның һәм авыл хуҗалыгының атаклы кешеләре белән бергәләп тикшерүне үзләренең эш практикаларына кертергә тиешләр. Болай эшләү бик кирәк һәм ул радиотапшыру эшен шактый яхшыртачак.

Совет радиотапшыруы үзенең 15 еллыгын бәйрәм итә. Партия һәм хөкүмәт җитәкчелегендә, иптәш Сталин җитәкчелегендә безнең илебездә радиотапшыру зур уңышларга иреште. Радио работниклары киләчәктә тагын да яхшырак эшләрләр, үзләрендәге кимчелекләрне бетерү өчен көрәшерләр. Совет радиосы ВКП(б) ның XVIII нче съездының тарихи карарларын уңышлы үтәүгә, коммунистик җәмгыять төзү өчен көрәшкә хезмәт ияләрен туплауда киләчәктә дә партиягә зур ярдәм итәр.

Г. Баталов.

ТАССР Совнаркомы янындагы радиокомитет председателе.

ТӨНГЕ СМЕНАЛАРГА ҖИТӘКЧЕЛЕКНЕ КӨЧӘЙТЕРГӘ

Цехлар арасында элемтә начар куелган

4 нче цехның смена начальнигы иптәш Викторова производствога шактый вакыт алдан килде. Эш урыннарын, машиналарны, материалларны җентекләп тикшереп чыкты. Житешсезлекләрне исәпкә алды, эш процессында аларның кабатланмавы өчен шартлар тудырды. Мастерлар белән сөйләште, аларның тегү ясау мәсьәләсе турындагы сорауларын канәгатьләндерде.

Смена үз вактында эшкә башлады. Кичегеп килүчеләр булмады. Алдынгы мастер иптәш Никитина (район советы депутаты) төнге сменаны үткәрүгә аеруча зур игътибар белән хәзерләнде. Ул фабриканың башка мастерларыннан үзенең эше, хезмәтне оештыру белән аерылып тора. Ул һәр вакыт игътибар бирә белүе белән аерылып тора. Ул смена башланганнан алып ахрына кадәр цехта, кешеләр арасында, машиналар янында булды. Аның җитәкчелегендә 56 кеше эшли. Шуларның 50 се стахановчылар. Эшчеләрнең барсы да стахановча эшләүләре өчен мастер бөтен шартларны тудыра.

Бу цехтагы төнге смена хезмәт дисциплинасының югары булуы өчен көрәшә. Әгәр дә хезмәт дисциплинасын бозу фактлары булса, һич кичекмичә, кирәкле чара күрелә. Мәсәлән, смена эшкә башлап шактый вакыт үткәч, Ольга Комарова тарафыннан хезмәт дисциплинасының бозылуы турында берничә эшче белдерү ясый. Смена начальнигы иптәш Викторова бу мәсьәләне шунда ук тәнәфес вакытында производство киңәшмәсен җыеп тикшерә. Киңәшмәгә эшчеләрнең барсы да катнашалар. Мастер иптәш Никитина сүз ала. Ул иптәш Комарованың житешсезлеген, хезмәт дисциплинасын бозуга юл куюын каты тәнкыйть итә. Аннан соң Гаврилова, Белашова һәм башка иптәшләр сүз алалар. Алар барсы да иптәш Комарованы тәнкыйть итәләр, аның житешсезлеген күрсәтәләр, производствода үрнәкле тәртип, нык дисциплина өчен көрәшкә барлык эшчеләрне чакыралар. Соңыннан иптәш Комарова сүз ала. Ул иптәшләренең күрсәтүләрен бик дөрес дип таба һәм моннан соң бер вакытта да хезмәт дисциплинасын бозмаска сүз бирә. Сменада ул башка көннәрдәгедән яхшырак күрсәткечләр биреп эшләргә өйрәнә һәм шуны үти.

Һәрбер эшчегә болай индивидуаль рәвештә якын килә белүнең нәтиҗәсендә гомуми күрсәткечләр үсә. Смена заданиене 110 процент итеп үтәүгә ирешә.

Өченче цехтагы төнге сменада зур житешсезлекләр булды. Хезмәтне һәм эш урыннарын дөрес оештыра белмәү күренде. Смена җитәкчеләре цехта күпме стахановчы барлыгын да ачык белмиләр. Алдынгыларның тәҗрибәләрен уртаклашу мәсьәләсе белән бер кем дә шөгыльләнми.

Бу сменада зур житешсезлекләрнең берсе итеп хезмәт дисциплинасының йомшак булуын күрсәтергә кирәк. Мәсәлән, ашханәдән 8 кеше дүртәр-сигезәр минутка кичегеп килделәр. Бу житешсезлекне бетерү өчен шунда ук чара күрелергә тиеш иде. Ләкин чара күрүче булмады. Мона смена җитәкчеләре „булып тора торган хәл инде ул" дип карыйлар. Ашханәдән 8 минутка соңга калып килүче Смолина бу турыда фабрика техноругы иптәш Веселовка әйтә, технорук: „ярый, соңга калгач калгансың инде", дию белән чикләнде. Мондый фактларны фабрика директоры иптәш Малюгин да белә. Ләкин ул да чара күрергә ашыкмый, ашханәгә зур тәртипсезлекләрне бетерү өчен үзе чаралар санамый.

Аннары, бик кызу эш барган вакытта подкладкалар житешмәве беленә. Цехта: „Кая киткән подкладкалар, нишләп алар юк" дигән тавышлар ишетелә. Тикшереп карагач, подкладкаларны кисү цехыннан бик соңга җиткерүләре беленә. Шуннан соң смена җитәкчеләре „Гаеп бездә түгел, гаеп бары кисү цехында гына. Алар безнең эшебезгә комачаулык китерәләр" дип үзләрен бик тиз акларга тотыналар. Кисү цехы начальнигы иптәш Кривошеев исә: „Сез беләсез инде, без гел эшләргә алмыйбыз" дип тыныч кына җавап бирә.

Ә гаеп цехларның икесендә дә бар иде. Алар төнге сменаларга җитәкчелекне тәэмин итмәделәр.

Икенче тегү фабрикасы эшчеләре төнге сменаларга җитәкчелекнең тамрыннан яхшыруын таләп итәләр. Аларның бу таләпләре бер сүзсез үтәлергә тиеш.

Г. Сәетев.

Казшвейпром артеленең алдынгы стахановчысы иптәш М. Волкова. Ул беренче квартал планын 10 нчы мартка 320 процент итеп үтәде. Н. Галиев фотосы.

Төнге смена ни өчен начар эшли

Смена башлануга әле бер сәгаттән артыграк вакыт бар. Шуңа карамастан, төнге сменада эшләүчеләр завод янына җыела да башладылар инде. Ераграк торучылар эшкә аеруча иртә киләләр. Бер сәгат аз вакыт түгел. Тик торган кешегә бу бер сәгат вакыт тагын да озаграк булып тоела. Буш вакыттан файдаланасы иде, радио тыңлыйсы, газета-журналлар укып, илнең яңалыклары белән танышасы иде дә бит, кызганычка каршы, язу машиналары заводында моңа мөмкинлек тудырылмаган.

Сменага килүчеләр өчен комендатура янында көтеп тору бүлмәсе юк. Шуңа күрә алар беренче сменада эш беткәнне урамда көтеп торалар. Кызыл почмак завод ишек алдына урнашкан. Анда беренче сменада эш бетми торып берәүне дә җибәрмиләр. Дөрес, каты буран булса, яки яңгыр явып ачык һава астында тору мөмкин булмаса, комендатурадан иртәрәк тә җибәрәләр. Ләкин мондый көннәр һәр вакыт булып тормый бит...

Смена эшкә башлаганда без механика цехында идек. Смена начальнигы иптәш Москвин эшләрен бетергәннән соң безнең янга килде. Без аннан төнге сменаларда хезмәтнең оештырылуын, хезмәт дисциплинасы һәм план үтәлеше турында сораша башладык.

— Эшлибез. Яхшы эшләгән чак та, начар эшләгән чак та була. Билгеле, төнге сменаларда хезмәт җитештерүчәнлеге көндезге сменаларга караганда кимрәк була инде ул,—ди иптәш Москвин.

План үтәлешен күрсәтә торган сводкадагы цифрлар да шушы турыда сөйлиләр. Иптәш Москвин сменасы мартның өченче биш көнлегендә көндезге сменада эшләп айлык планның 20,1 процентын үтәсә, икенче биш көнлектә төнге сменада эшләп айлык планның 13процентын гына үтәгән.

Иптәш Москвин план үтәлешенә комачаулый торган сәбәпләр эзләп табарга тырышып карады, әлбәттә. Ләкин төнге сменаларда хезмәтнең тиешенчә оештырылмавы, хезмәт дисциплинасының йомшак булуы турында бер сүз дә әйтмәде. Ә төнге сменаларда хезмәт дисциплинасын бозу фактлары бар. Слесарь Гаранин безнең күз алдыбызда эшкә берничә минутка соңга калып килде. Яки менә хезмәтнең начар оештырылуын күрсәтә торган тагын бер факт алыйк. Күптән түгел генә өйрәнчек итеп алынган иптәш Остудина төнге сменага чыккач станок булмау аркасында смена буе тик торган. Бүген аны бер буш станок янына куйсалар да, ул станокның бер часте җитешмәү аркасында, иптәш Остудина озак вакытлар эш башлый алмый торды.

Эшчеләр кечкенә генә сәбәпләр аркасында төнге сменаларда станокларның тик тору фактлары бик күп булуы турында сөйлиләр. Ләкин язу машиналары заводы җитәкчеләре төнге сменаларда очрый торган һәм план үтәлешенә комачаулый торган мондый сәбәпләр белән кызыксынмыйлар. Хезмәтне оештыруда булган җитешсезлекләрне бетерү өчен чаралар күрелми.

Төнге сменаларда эшләүчеләр арасында политик-масса эшләре алып бару, әһәмиятле мәсьәләләрне эшчеләргә үз вактында җиткерү белән партия, комсомол оешмалары да, профсоюз оешмасы да шөгыльләнмиләр. Кызыл почмак, көтепханә төнге сменаларда бөтенләй эшләми.

Төнге сменаларда эшләүчеләрне җәмагать туклануы белән тәэмин итү эшендә дә бик күп җитешсезлекләр яшәп килә. Аш җитми калу фактлары бар. Отделка цехы мастеры иптәш Верин: „Мин төнге сменада эшләгән вакытта эшчеләрне бер сәгат эшләгәч тә ашарга җибәрәм. Чөнки тәнәфесне көтсәң ашарга бер әйбер дә калмый" ди.

Завод җитәкчеләре бу җитешсезлекләргә карата чара күрергә һәм төнге сменаларга җитәкчелекне көчәйтергә тиешләр.

Сагдеева, Закирова, Вахитов.

СВОДКАЛАРГА КАРАП ФИКЕР ЙӨРТӘЛӘР

Төнге сменаларда хезмәт җитештерүчәнлеге кимрәк була инде ул,—ди иптәш Семенов.

Беренче номерлы икмәк заводы директоры иптәш Семенов өстәленә куелган сводкадагы саннарга карап шундый нәтиҗә ясый. Ә төнге сменаларда эшнең барышын күзәтеп торсаң, башка төрле нәтиҗәләр ясарга мөмкин.

Менә арыш икмәге пешерү цехының берничә көнлек эшен алып карыйк. 25 нче мартта көндез эшләгән икенче бригада сменага 34,2 тонна икмәк пешергән, ә төнлә эшләгән смена 36,3 тонна икмәк пешергән. Димәк, эшне дөрес оештырганда, оборудованиеләрдән тулы файдаланганда төнге сменалар, хәтта күбрәк тә эшләп чыгара алалар. Чөнки бригадаларда кешеләр саны да, эш шартлары да бер үк төрле. Ләкин еш кына хәлләрдә, төнге сменаларда эштә тоткарлык күбрәк була. Мәсәлән, 26 нчы мартка каршы төндә, Закиров сменасында, камыр изү машинасының моторында кечкенә бер шкив ватыла һәм бу машина бер сәгаттән артык эшләми тора. Бу инде үз чиратында формовка машинасына да, шулай ук пичләрнең дә эшенә тоткарлый. Нәтиҗәдә бригада гадәттә пешерелә торган 36—37 тонна урнына, бу сменада бары 32 тонна гына икмәк пешерә.

Моторның төзек булмавы турында бригадир иптәш Закировның шул вакытта ук производство мөдире иптәш Арининга язма рәвештә белдерүе булуга да карамастан, моторны төзәтүче булмый. Шул ук шкивның ватылуы нәтиҗәсендә, 27 нче мартка каршы төндә камыр изү машинасы тагын 2 сәгат эшләми торды. Бу сменада эшләүче иптәш Соловьев бригадасы да планны үти алмады, бары 31,6 тонна гына икмәк пешерде.

Димәк, икмәк заводында төнге сменаларга тиешле техник җитәкчелек тәэмин ителмәгән. Монда барлык машиналарның һәм механизмнарның эшен күзәтү җитәрлек квалификациясе дә булмаган бердән бер дежурный слесарьга гына йөкләтелә. Машиналарның туктап торуларын, техника куркынычсызлыгы чаралары начар куелганлыктан соңгы вакытта булган бәхетсезлеккә очрау фактларын да шуның белән аңлатырга кирәк.

Заводта эшчеләрнең алмашынып торуы, прогул ясау фактлары еш кабатлана. Мәсәлән, венский цехта, 27 нче мартка каршы төндә, иптәш Ивойлов бригадасыннан эшче Яковлев прогул ясады. Бу сменада цех 9 оборот урнына 8 генә оборот бирде, заданиене үтәмәде.

Мондый хәлләр заводта еш булалар. Төнге сменаларда эшләүчеләр арасында бернинди дә агитация-масса эше алып барылмый. Кызыл почмак төнлә һәр вакыт ябык була. Эштәге специфик сәбәпләр аркасында цехларда тәнәфес булмый. Ләкин монда агитация-масса эшләре алып барырга вакыт бар. Эшчеләр төнге сменаларга шактый иртә киләләр. Алар коридорларда, гардероб янында җыелалар да, звонок булганны көтеп бик күп вакытларын бушка уздыралар. Алар белән беседа ясаучы да, кычкырып газета укучы да булмый. Эшчеләр үзләре укырга теләсәләр дә, төнге сменада газета-журнал таба алмыйлар. Заводның бер участкысыннан икенчесенә туктаусыз йөгереп йөрүче смена начальнигыннан башка бер кем дә төнге сменаларда заводка килеп карамый.

З. Габитов.

ПРОИЗВОДСТВОДА НЫКЛЫ ЭКОНОМИЯ РЕЖИМЫ БУЛДЫРЫРГА

1939 нчы елгы отчетларга һәм балансларга анализ ясаганда, күп кенә предприятие җитәкчеләренең партия һәм хөкүмәт директиваларын тормышка ашыру өчен большевикларча көрәшмәүләре, хуҗалык исәбен ныгыту эшенә, дәүләт средстволарын дөрес һәм экономияле тотуга, эчке резервлардан файдалану мәсьәләсенә чиктән тыш гамьсез караулары күренә. Хәтта производство күрсәткечләре азмы-күпме яхшы үтәлгән предприятиеләрдә дә план-финанс дисциплинасының торышы түбән, алар әйбернең үзенә төшү бәясен киметү һәм рентабельлекне арттыру өчен ныклап көрәшмиләр.

Мисальгә „Строитель" кирпеч комбинатын (директоры иптәш Игнатов) алырга мөмкин. Бу комбинат бер генә күрсәткеч буенча да планны үтәми. Комбинат 1939 нчы елны 1 миллион 147 мең сум зарар күргән. Комбинатның җитәкчеләре моны объектив сәбәпләр белән аңлатмакчы булалар, ә фактлар исә бөтенләй башка нәрсә күрсәтәләр. Мәсәлән, 2 миллион данә чи кирпеч, администрациянең җавапсызлыгы нәтиҗәсендә, яраксыз хәлгә килгән. Комбинат монардан 114 мең сум зарар күргән. Комбинатның торак хуҗалыгы эшне үз агымына кую нәтиҗәсендә 243 мең сум зарар иткән. Начар сыйфатлы кирпеч эшләп чыгарудан 145 мең сум зарар килгән. Хуҗасызлык нәтиҗәсендә комбинат үзенең оборот средстволарын бөтенләй тотып бетергән.

„Кызыл Шәрык" заводы (директоры иптәш Фомин) 1939 нчы елны оборот средстволарыннан файдалана белмәү аркасында, финанс кыенлыклары кичерде, бу хәл аның производство эшенә дә комачаулады. Берничә еллар буенча заводның әллә никадәр алачагы җыелган. 1939 нчы ел башында бу алачак 1 миллион 773 мең сум иде һәм бөтен ел буена да шуннан кимемәде. 1940 нчы елның 1 нче январена булган баланс буенча завод „дебиторлык бурычы 658 мең сумга кимеде" дип күрсәтә. Чынлыкта исә, завод „балансын чистарткан" гына һәм баланс дөрес булып күренсен дип, 613 мең сум алачакны зарар исәбенә язган. Шул исәпкә растратчиклардан эзләнеп алынырга тиешле булган 333 мең сум да кертелгән. Заводта растрата һәм урлаулар нык тамыр җәйгән. Завод җитәкчеләре хөкүмәт акчасын урлаучыларга каршы көрәш алып бармыйлар. 1938 нче елны 365 мең сум акча туздырылган булса, 1939 нчы елны бу сума 449 мең сумга җиткән.

„Спартак" комбинаты продукция эшләп чыгару планын 100,8 процент итеп үтәде. Ләкин предприятие җитәкчеләре (директоры иптәш Ситников) производствода сыйфат өчен көрәшне һәм югалтуларга каршы көрәш мәсьәләләрен арткы планга куйганнар. Хуҗасызлык нәтиҗәсендә комбинат 1939 нчы елны 1 миллион 470 мең сум зарар күрде.

Бу предприятиеләрнең җитәкчеләре быел да җавапсызлык күрсәтәләр. Мәсәлән, Ленин исемендәге күн заводында январь аенда гына да директор фонды исәбенә 3,3 мең сум, цех расходлары буенча 41 мең сум артык расход тотылган. Дебиторлык бурычлары бер ай эчендә 388 мең сумнан 644 мең сумга кадәр үскән.

„Спартак" комбинатында февраль аенда дебиторлык бурычлары 34 мең сумга арткан, хезмәт хакы фонды 69 мең сумга, цех расходлары (январь — февраль аенда) 142 мең сумга артык тотылган. „Строитель" комбинатында дебиторлык бурычлары январь аенда 33 мең сумга арткан һәм 21 мең сум зарар күрелгән.

Промышленность наркоматлары үзләренә буйсындырылган предприятиеләрнең хуҗалыгы һәм финансы өстеннән тиешенчә контроль алып бармыйлар. Наркомат работниклары предприятиеләрнең балансларына күз салуны, аларның отчетларын өйрәнүне һәм хуҗалык исәбе турында кайгыртуны үзләренең бурычлары дип санамыйлар. Мәсәлән, Наркомлегпромның финанс бүлеге начальнигы иптәш Гиммельфарб балансларга анализ ясау эше белән шөгыльләнми. Наркомместпромның финанс бүлеге начальнигы Сабитов һәм төзү материаллары идарәсеннән Борисова иптәшләр, предприятиеләрнең финанс-хуҗалык эшен әледән-әле күзәтеп тору һәм средстволарны дөрес файдалануда аларга вактында ярдәм итү урнына, финанс өзеклекләрен каплау өчен бюджеттан акча сорап, Наркомфиннан китми яталар.

Аннары наркоматлар үзләре дә начар якка таба үрнәк күрсәтәләр. Мәсәлән, Наркомместпром, тулы булмаган штат исәбенә ясалган 18 мең 800 сум экономияне законсыз тоткан. Шушы экономия исәбенә работникларга югары ставка бирүгә, бәйрәм көннәрендә дежур торган өчен һәм артык эш сәгатьләре өчен түләгәннәр, „еллык отчет төзегән өчен" дигән булып, счет работникларына өстәмә хезмәт хакы биргәннәр. Наркомлегпром штаттан тыш 8 работник тоткан һәм аларга ай саен 2.894 сум акча түләп килгән. Бу наркоматларның җитәкчеләре, дәүләт средстволарын тотуга үзләре җиңел караш күрсәткәнлектән, алар, әлбәттә, предприятиеләрдән саклык һәм дисциплиналылык таләп итә алмыйлар. Киресенчә, средстволарны урынсыз тотучыларга юл куялар. Мәсәлән, җиңел промышленность наркоматының элекке наркомы иптәш Валеттинов предприятиеләргә оборот средстволарын социаль-көнкүреш расходларына тоту турында күрсәтмәләр биргән. Хәзерге наркомның урынбасары иптәш Ковальский да шундый ук юлны тота. Ул Казан киез итек фабрикасы директоры иптәш Вязовкинга директор фондын законда күрсәтелгәннән артык тотарга рөхсәт биргән. План бүлеге начальнигы иптәш Цукерман, 1939 нчы елны тотылган артык расходларны тикшергәндә, фабриканың баш бухгалтерына, син законсыз расходларны кайда һәм ничек яшерергә әле һаман өйрәнмәгәнсең, дип үпкә белдергән.

Азык промышленносте наркомы иптәш Латыйпов 1939 нчы елны, „Кызыл Шәрык" заводы работникларын директор фондыннан бүләкләргә дип приказ чыгарган, ә фактта исә директор фонды бөтенләй булмаган.

Шунсы характерлы, Татнаркомфин иптәш Латыйповның бу приказына каршы протест белдергәч, Совнарком консультанты иптәш Рәҗәпов Латыйповны яклап чыга һәм бу мәсьәләне Совнарком карамагына кертми калдыра. Иптәш Рәҗәпов һәм Госплан консультанты һәр вакыт промышленность наркоматларын яклыйлар. Промышленностьның начар эшләве турында Татнаркомфин тарафыннан бирелгән сигналлар һәм докладнойлар, ни өчендер, күбрәк хәлләрдә иптәш Рәҗәпов һәм Госплан консультанты кәгазьләре арасына кереп югалалар. Совнарком карамагына кертелмиләр. Бу мәсьәләдә Наркомфин үзе дә йомшаклык күрсәтә, промышленностьның эше турындагы мәсьәләләрне Совнарком алдына конкрет итеп куймый.

Г. Иванов.

Татнаркомфинның халык хуҗалыгын финанслау бүлеге начальнигы.

Чит илләрдә

КЫЗЫЛ АРМИЯ ТУРЫНДА „НЬЮ-ЙОРК ТАЙМС“ ГАЗЕТАСЫ

НЬЮ-ЙОРК, 27 март. (ТАСС). Американың Финляндиядә сугыш хәрәкәтләре вактында Кызыл Армия турында күп кенә ялган информация урнаштырып килгән буржуаз матбугаты хәзер элек иглан ителгән ялган информациягә тулысынча капма-каршы килә торган хәбәрләр урнаштырырга мәҗбүр була. Февраль аенда „Нью-Йорк таймс“ газетасы Маннергеймның „җиңүләре“ турында үзенең Хельсинкидагы хәбәрчесенең күп кенә хәбәрләрен урнаштырган иде. Ләкин хәзер газета элек урнаштырып килгән ялган хәбәрләрен юкка чыгарырга мәҗбүр була. Монда Кызыл Армия турында дөрес информация таләп итүче укучыларның басымы аеруча сизелә. „Нью-Йорк таймс“ газетасы, февральдә үзе басып чыгарган ялган хәбәрләрне искә алмыйча, 26 нчы мартта Норт Америкэн Ньюс агентлыгы хәбәрчесе Олдричның хәбәрен басып чыгарды. Бу хәбәрче Кызыл Армиянең сугыш куәте турында тулы итеп яза. Олдрич сугыш хәрәкәтләре вактында Финляндиядә булган, ә хәзер Стокһольмдә. Олдрич, совет бомбардировщиклары бик яхшы дип яза. „Совет истребительләре нинди генә дошманның самолетларына караганда да нәтиҗәлерәк һәм яхшырак“. Совет истребительләре финнәргә совет шәһәрләрен бомбага тотарга ирек бирмәделәр. Совет авиациясе бик яхшы тәэмин ителгән, ә очучылар очу эше өлкәсендә дә, шулай ук бомбалар ташлау өлкәсендә дә яхшы хәзерләнгәннәр һәм өйрәтелгәннәр. Аннары Олдрич дошман самолетларының тактикасын совет очучылары бик яхшы аңлыйлар дип күрсәтә. Совет самолетында төп пилоттан тыш күзәтүчеләр дә һәм экипажның башка членнары да самолетны йөртә беләләр. Совет очучылары бик яхшы коралландырылганнар. „Нью-Йорк таймс“ газетасы бу хәбәрне түбәндәге зур баш астында бирә: „Совет һава көчләре гаят көчле; бомбардировщиклары һәм истребительләре бик нәтиҗәле. Финляндиядәге күзәтүчеләр яхшы өйрәтелгән һәм яхшы коралландырылган очучылары булган хәзерге заман самолетларын күрделәр“.

ФИНЛЯНДИЯДӘ ЯҢА КАБИНЕТ

ЛОНДОН, 27 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, бүген Рюти Финляндиянең яңа кабинетын төзегән. Кабинет составына баш министр Рюти, чит ил эшләре министре Виттинг, юстиция министре Лехтонен, эчке эшләр министре барон Фон-Борн, тәэминат министре Таннер, оборона министре генерал Вальден һәм финанс министре Пеккала кергәннәр.

СТОКҺОЛЬМ, 28 март. (ТАСС). Финляндиянең яңа кабинетының тулы составы турында Финляндиянең информация бюросы түбәндәгеләрне тапшыра: баш министр—Финляндия банкысы директоры Ристо Рюти, чит ил эшләре министре—профессор Рольф Виттинг, юстиция министре—Оскари Лехтонен. эчке эшләр министре—Эрнст Фон-Борн, сугыш министре—генерал-майор Рудольф Вальден, финанс министре—Мауно Пеккала, мәгариф министре—Антти Кукконен, җир эшләре министрләре—Пекка Хейккинен һәм Юха Койвисто, юл эшләре һәм җәмагат эшләре министрләре—Вайно Саловаара һәм Карл - Эрик Экхольм, сәүдә һәм промышленность министре—Вайно Котилайнен, социаль тәэминат министре—Карл Фагерхольм, тәэминат министре—Таннер.

Шулай итеп хөкүмәтнең элекке составыннан яңа кабинетка элекке юстиция министре—Седергольм, элекке мәгариф министре—Ханнула, элекке хәрби министр—Нюканен, элекке тәэминат министре—Фиандт һәм элекке портфельсез министр—Паасикиви кермәделәр.

Көнбатыш Европа сугышы

ЛОНДОН, 28 март. Авиация министрлегенең хәбәр итүенә караганда, кичә разведка вактында Англия самолетлары Төньяк диңгездә Германиянең сакчы карабын батырганнар.

ЛОНДОН, 27 март. Кичә Төньяк диңгездә Англиянең 5.742 тонна авырлыктагы „Дагестан“ танкеры батырылган. Команданың 16 кешесе Шотландия ярына төшкән. 4 кеше һәлак булган. Англиянең күптән инде билгеләнгән урнына килмәгән 6.574 тонна авырлыктагы „Кэстлмур“ пароходын баткандыр дип уйлыйлар.

Англиянең „Арк Ройял“ авианосецы океанда 5 ай йөргәннән соң үзенең базасына кайткан.

БЕРЛИН, 27 март. Германиянең 16 нчы февральдә Англиянең сугыш караблары һөҗүм иткән „Альтмарк“ пароходы бүген Кильгә кайткан.

НЬЮ-ЙОРК, 27 март. Голландиянең „Протинус“ траулеры Төньяк диңгездә минага бәрелеп баткан. Англиянең сугыш карабы команданың 8 кешесен коткарган. 8 кеше хәбәрсез югалган. (ТАСС).

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА. Суйюань провинциясенең көнбатыш өлешендә кытай гаскәрләре Уюаньны алганнан соң японнарны эзәрләп баруларында дәвам итәләр. Кытайларның бер отряды Уюаньнан 60 километр көнчыгыштарак Сишаньчжуйдан японнарны бәреп чыгарган. Икенче бер отряд Баотоудан 25 километр көнбатыштарак Улашань районының көнчыгыш өлешен алган.

Уюаньда үтерелгән японнар арасында гарнизон начальнигы генерал Мидзукава да булган. Бэйпиннан көнбатыштарак кытай партизаннарына каршы көрәшү өчен җибәрелгән 700 кешелек япон отряды үзенең базасына чигенергә мәҗбүр булган. Кытайлар 17 пулемет, 170 винтовка, 400 ат һәм шактый күп сугыш кирәк-яраклары кулга төшергәннәр.

КӨНЬЯК КЫТАЙДА. Япон гаскәрләре Линьшань районыннан чигенүләрендә дәвам итәләр. Кытай гаскәрләре Кантоннан көньяк-көнбатышта Синьзой секторында 1.000 кешелек япон отрядына һөҗүм иткәннәр. Японнар чигенергә мәҗбүр булганнар.

ҮЗӘК КЫТАЙДА. Янцзы елгасының көньяк ярында, Аньхуэй провинциясендә 25 нче мартта япон гаскәрләре кытайларның позицияләренә һөҗүм ясаганнар һәм бу позицияләр ике тапкыр кулдан кулга күчеп торганнар.

ИТ ТАПШЫРУ ПЛАНЫН ӨЗӘЛӘР

ЧИСТАЙ. (**Телефон буенча**). Чистай районы дәүләткә ит тапшыру планын елдан-ел өзеп килә. Үткән ел колхозларда еллык план бары тик 82 процент, эшчеләр һәм хезмәткәрләр буенча 80 процент һәм аерым хуҗалыклар буенча 25 процентка гына үтәлүе, моның ачык мисале булып тора. Район җитәкчеләре, барыннан да элек Уполнаркомзаг вәкиле, бу хурлыклы артта калудан тиешле политик нәтиҗә ясарга, үткән елгы өзеклекне быел булдырмау өчен барлык чараларны күрергә тиешләр иде. Ләкин практикада бу конкрет чара хәзергә күренми әле.

Алар, дәүләткә ит тапшыру эшенә конкрет җитәкчелек итү урнына, туктаусыз киңәшмә үткәреп, озын-озын карарлар чыгару белән чикләнәләр. Ә ахырда үз карарларының үтәлеше белән кызыксынмыйлар. Менә шушылар нәтиҗәсендә 1940 нчы елның беренче кварталы планы 30 процентка гына үтәлгән.

Аерым авыл советларында һәм колхозларда бу эш тагын да начаррак куелган. „Большевик“, „Красный пролетарий“, „Красный ключ“, „Красный луговик“, Калинин һәм Сталин исемендәге колхозлар ит тапшыруның беренче квартал планын 2 — 5 процентка гына үтәгәннәр. Ә Тат. Талкыш, Актау, Байтирәк, Бахта, Иске Ванаево авылларындагы аерым хуҗалыклар 1940 нчы ел хисабына бер килограмм да ит тапшырмаганнар.

Районда дәүләткә ит тапшыру эшен яхшы оештырган колхозлар да юк түгел. „Урожай“, „Красный Октябрь“, „Завет Ильича“, „Красный Бор“ колхозлары дәүләткә ит тапшыру планын үткән елда 100 процентка үтәгәннәр иде. Алар 1940 нчы елны да планны 50—80 процентка үтәделәр. Районда алдынгы колхозларның һәм авыл советларының уңышлы тәҗрибәләрен артта калучыларга күчерү эше белән шөгылләнмиләр. Дәүләткә ит тапшыру планын өзүче хуҗалыклар җавапка тартылмыйлар.

К. Исламов.

Г. ТЕЛӘШ.

ИҖАД

(Шәриф ага Камалга багышлыйм)

Хиялымда минем бер матур бар,
Күз алдымда басып тора ул,
Минем кебек яши, уйный, көлә,
Яңалыкны төзи, кора ул.
Яшлек белән сөя җирнең
матурлыгын,
Дәртле сулый чәчәк исләрен.
Язгы ярсу белән яраткандай
Чикли белми иркен хисләрен.
Минем кебек саф күңелле
булып
Уйларына хезмәт кабынган.
Ул хиялны әгәр бар итә алсаң
Озон аңкый аның яныннан.
Кем ул? Хиялымда урын тапкан?
Мәңге булган җырчы юлдашы?
Кабер кебек салкынлыкта
калганда да
Һич кызганмый дуслык кояшын.
Ул җиткерә минем уйларымны
Халыкларның тирән аңына.
Ул ярата барлык шатлык, ямне
Кул салмый ул шагыйрь данына.
Ул күтәрә ваклык, түбәнлектән,
Галилеккә таба югары—
Алгы сафта штурмга барган
батыр
Тоткан төсле сугыш байрагын.
Иҗад—шулай хиялдагы матур
кебек
Уйларыма минем кабынган.
Мин дә аңа, ул да миңа,
Кайнар сөю белән сарылган.
Хиялымда минем бер матур бар,
Күз алдымда басып тора ул.
Минем кебек яши, уйный, көлә,
Яңалыкны төзи, кора ул.
Менә шундый, иҗад
батырлыгын
Йөрәгендә мәңге саклаган,
Гомерендә булган һәр адымын
Аның белән бергә атлаган.
Шәриф ага, утыз еллык иҗад
көчең
Котлау өчен җырым кабынган.
Сокланырлык матур синең
гомер
Якын төсле тоела барыннан.
Батырлыгың синең арта, үсә
бара
Моңа шаһит үткән эзләрең.
Җан азыгы була шат халыкка
Күтәренке, ачык сүзләрең.
Киләчәгең якты яшлек кебек
Кем сокланмас мондый язмышка,
Дошман сафын һаман тар-мар
итә,
Әсәрләрең канлы сугышта.
Йөрәк җырым бөек хөрмәт
белән
Синең эштән тагын кабынды.
Эраларга җитсен синең хезмәт
диеп
Киләчәген өзелеп сагынды.

1940 ел, март. Казан.

КАРДӘШ РЕСПУБЛИКАЛАРДАН ВӘКИЛЛӘР

Шәриф Камалның юбилей тантанасында катнашу өчен Казанга кунаклар килүдә дәвам итә. Кичә Мордовиядән шагыйрь З. Вечканов, Башкыртстаннан Диянов һәм Горький краеннан М. Исхаков иптәшләр килделәр.

Юбилей көннәрендә язучының туган авылы Пешләдә аеруча зур җанлылык күренә. Бүген авылда әдәби кичә үткәрелә. Пешлә авылының тулы булмаган урта мәктәбенә Шәриф Камал исеме бирелде.

ЯУЛАП АЛЫНГАН УҢЫШЛАР

Казан галантерея фабрикасы коллективы Татарстанның XX еллыгын лаеклы рәвештә каршылау өчен зур хәзерлек эшләре алып бара. Фабрикада социалистик ярыш көннән көн киңәя. Төймә цехы стахановчылары Черкасова һәм Пенькова иптәшләр көнлек норманы 230—250 процент итеп үтиләр.

Фабрика 1940 нчы елның 1 нче квартал планын 22 нче мартта ук тулысынча тәгәлләде. Коллектив 1 нче апрельгә кадәр планнан тыш 90 мең сумлык киң куллану товарлары эшләп чыгару йөкләмәсен алды.

М. Шабай.

Допризывниклар—оборона эше активистлары

Чистай шәһәрендә судноларга ремонт ясау заводы допризывникларының җыелышы булды. Җыелышта призывка яхшы хәзерләнү өчен Алексеевский районы белән ике арада төзелгән социалистик ярыш договорының үтәлешенә йомгак ясалды.

Допризывниклар—производствода алдынгы эшчеләр. Заводта эшләүче 183 допризывникның 132 се стахановчы. Алар Кызыл Армиянең лаеклы сугышчылары булырга җидди рәвештә хәзерләнәләр. Допризывникларның 89 процентының ПВХО значоклары, 83 процентының ГСО значоклары бар. 130 кеше чаңгыда йөрү буенча һәм 138 кеше граната ыргыту буенча нормалар тапшырды. Күп кенә допризывникларның 3—4 оборона значоклары бар.

Судноларга ремонт ясау заводы допризывниклары су юллары ачылганга кадәр оборона значокларына норма тапшыруны тәгәлләргә һәм аз укый-яза белүчеләрне тулысынча укуга тартырга карар бирделәр.

ТРАКТОРЧЫЛАР ЯҢАДАН МТС КА КАЙТАЛАР

Моннан 2—3 ел элек Лаеш районында күп кенә тракторчылар һәм тракторчы хатын-кызлар төрле сәбәпләр белән МТС та эшләүне ташлаганнар иде. Хәзер алар тракторда эшләү өчен яңадан МТС ка кайталар.

ХАЛЫК ИҖАДЫ ОЛИМПИАДАСЫ

23 нче мартта Аксубайда, Татарстан АССР ның XX еллыгына багышлап, халык иҗадының район олимпиадасы ачылды. Олимпиадада педучилищедән, мәктәпләрдән, МТС тан, колхозлардан, „Большевик“ совхозыннан һәм башкалардан 29 коллектив катнаша. Драма һәм хор түгәрәкләре, кыллы һәм тавышлы оркестрлар, әкиятчеләр, декламаторлар, биючеләр, физкультурниклар һәм башкалар үзләренең иҗадларын күрсәтәләр.

ПВХО ИНСТРУКТОРЛАРЫ ХӘЗЕРЛӘҮ

Осоавиахимның Алабуга район советы, ПВХО инструкторлары хәзерләү өчен Осоавиахимның башлангыч оешмалары председательләренең 8 көнлек семинарын үткәрде. 22 кеше ПВХО инструкторы дигән исемне алды һәм алар колхозларда эшкә керештеләр. (ТатТАСС).



27 нче мартта, укучы балаларның гимнастика буенча кустовой ярышлары тәмам булды. РӘСЕМДӘ: үсмер кыз балалар группасында 1—2 нче урыннарны бүлешкән Т. Кулакова (Куйбышев) һәм М. Сутягина (Казан); түбәндә—кустовой ярышларда абсолют беренче урынны алган Д. Крейнин (Казан), үсмер ир балалар группасында икенче урынны алган С. Карыгин (Куйбышев) һәм өченче урынны алган Л. Рылов (Ижевск) иптәшләр.

И. Галиев фотосы.

ТАТАРСТАНДА

Куйбышев гидроузелы төзелү уңае белән Казан—Чкалов тракты линиясен беркадәр үзгәртү күздә тотыла. Бу тракт Казаннан Чистайга Тугаш авылы аркылы үткәреләчәк.

***

Татарстан Халык Комиссарлары Советы янында аучылык буенча дәүләт инспекциясе төзелде. Инспекция аучылык кагыйдәләренең төгәл үтәлүен күзәтеп торачак.

***

Казанда Кинопленка һәм фото-желатина заводы төзелешләренә 1940 нчы елга 20 миллион 580 мең сум акча билгеләнде. Узган ел бу төзелешләргә 22 миллион 98 мең сум тотылган иде.

***

Татарстанда дәүләттән ярдәм алучы пенсионерларның саны 26 меңнән артыграк. Быел аларга дәүләт бюджетыннан 24 миллион сумнан артык пенсия түләнәчәк.

***

Мамадыш районының „Хәсәнша“ колхозында төлкеләр фермасы оештырылды. Фермага, Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә кандидат итеп билгеләнгән иптәш Исмагыйлов җитәкчелек итә.

***

Кызыл Армия районының Каргалы МТС ында орлыкларны яровойлаштыру һәм агулау буенча 5 көнлек курс-семинар үткәрелде. Биредә барлыгы 18 кеше укыды, аларның 11 е хатын-кызлар.

ЯҢА ПИТОМНИКЛАР

Хәзерге көндә Татарстанда җиләк-җимеш агачлары үстерә торган 25 питомник бар. Алар алмагачлар, чия агачлары, кура җиләге, крыжовник, карлыган куаклары һәм башкаларны үстерәләр.

Колхозларда бакчачылык эшен тагын да киңәйтү, шулай ук колхозчыларның һәм районнарда торучы эшчеләрнең, хезмәткәрләрнең каралты тирәләренә җимеш агачлары утыртуга булышлык күрсәтү өчен быел һәм киләсе елда Татарстан колхозларында 135 гектар мәйданда яңадан 10 питомник оештырыла. Әгерҗе, Балтач, Тәкәнеш һәм Сарман районнарында питомникларны оештыру эше башланды инде. Питомникларда эшләү өчен 2 айлык курслар аркылы 50 бригадир хәзерләнә. Җимеш агачларын ялгарга өйрәтү өчен 15 көнлек курслар оештырыла. Курсларда 250 кеше хәзерләнәчәк.

КОЛХОЗЛАРДАГЫ ҮЗЕШЧӘНЛЕК ТҮГӘРӘКЛӘРЕ ОЛИМПИАДАСЫ

Татарстанның XX еллыгына хәзерлек уңае белән Ютазы районының барлык колхозларында да үзешчәнлек түгәрәкләре олимпиадасы үткәрелде. 24 нче мартта район олимпиадасы булды, анда гармончылар, җырчылар, биючеләр һәм декламаторлар катнашты. Олимпиадага катнашучылардан 13 кешегә бүләкләр бирелде.

Бүләкләнүчеләр арасында 67 яшьлек колхозчы биюче иптәш Әхмәтҗан Нурхәлимов та бар. Гармончы Арслан Нурзакиев, „Кызыл бүләк“ колхозы члены җырчы Ислам Бикмуллин иптәшләр олимпиадада беренчелекне алдылар. Олимпиадага катнашучылардан биш кеше республика олимпиадасында катнашу өчен Казанга барачак.

КӨНДӘЛЕК ВАКЫЙГАЛӘР

Бәхетсезлеккә очрау. Фәридә Хәнәфиева дигән 8 яшьлек кыз Кремль тавыннан чана шуган вакытта бәхетсезлеккә очраган. Бауман районы төзү конторасының йөк автомобиле Батурин тыкрыгында аны таптап бик каты имгәткән. Хәнәфиева больницага алып барган вакытта үлгән.

Татарстан Кинофикация Трестының шоферы Ситнов 58—88 нче автомобиль белән Киров урамыннан барганда Ишина дигән яшьлек кызны таптаткан. Кызны авыр хәлдә больницага озатканнар. Шофер җавапка тартыла.

Редактор урынбасары
И. ҮЗБЕКОВ.
Зам. редактора И. УЗБЕКОВ.

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
30 һәм 31 нче мартта, шулай ук, 1 һәм 2 нче апрельдә премьера
ТАНЯ
Талоннар белән кертелми.
Спектакль кич 7 сәгать 30 минутта башлана
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 30 нчы мартта көндез 12 сәгатьтә
ЛЕНИН
Бүген кич, шулай ук 1, 2 һәм 3 нче апрельдә Б. Шкваркин әсәре премьера
„КУРКЫНЫЧЛЫ СУД“
Талоннар белән кертелми.
Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
31 нче мартта Зур театр бинасында
ФАУСТ
3 нче апрельдә
Татар Дәүләт Академия театры бинасында
ФАЙДАСЫЗГА САКЛАНУ
Талоннар белән кертелми.
Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген һәм һәр көн
ФРАНЦУЗЧА КӨРӘШ
(Һәр көн 3 пар көрәшә)
һәм зур программа буенча
ЦИРК УЕНЫ
Бүген, 30 нчы мартта
ЗУР ПРОГРАММАДА
КӨНДЕЗГЕ ЦИРК УЕНЫ
Уен көндез 12 дә, кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 11 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 10, 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, художестволы яңа фильм ЗУР ТОРМЫШ
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8, һәм 10 да.	ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР (Соңгы көннәре)
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 2, 4, 6, 8, 10 да.	ВОЛГА-ВОЛГА
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9-30 да.	ДИПКУРЬЕР СУМКАСЫ
„ПИОНЕР“ 10, 11-30, 1, 2, 3-30, 5, 6-30, 8-20.	ШӘХСИ ЭШ Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП
„РОТ-ФРОНТ“ 6, 8, 10 да.	Гроза
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	20 ЕЛ ЭЧЕНДӘ КИНО

Татарстанның фәнни учреждениеләре

ФӘННИ-ТИКШЕРЕНҮ ВЕТЕРИНАРИЯ ИНСТИТУТЫ

Казан Фәнни-Тикшеренү Ветеринария институты 1931 нче елның апрелендә, аңарчы яшәп килгән Край Ветеринария Бактериология институты базасында оештырылды.

Бактериология институты составында 9 ветврач бар иде. 1940 нчы елның 1 нче январена Фәнни-Тикшеренү Ветеринария институты составында эшләүче фәнни работникларның саны 27 гә җитте. Алардан 7 се—ветеринария фәннәре кандидатлары.

Шушы 9 ел эчендә институт күп кенә фәнни проблемаларны эшләүдә зур уңышларга иреште. Шуның өчен ул Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашты һәм беренче дәрәҗәле диплом алды. Бу уңышларның бөтенесенә партиянең, хөкүмәтнең һәм иптәш Сталинның фәнне үстерү турында көндәлек кайгыртучанлык күрсәтүләре һәм җитәкчелек итүләре аркасында ирешелде.

1939 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашу өчен безнең институттан 1 кеше гариза биргән иде. 1940 нчы елда 7 кеше гариза бирде. Бу хәл институтта иҗад эше өчен базаның һәм тиешле шартларның артканлыгын күрсәтә.

Яңа форма белән эшләү, ягъни фәнни проблемаларны берничә фәнни работникның катнашы белән бергәләп тикшерү нигезендә институт 1937—1939 нчы елларда күп кенә фәнни мәсьәләләрне эшләде һәм практикага кертте.

Патологик анатомияне, патологик гистологияне һәм патологик физиологияне өйрәнү, шулай ук терлекләрдә була торган йогышлы энцефаломиэлит (хәйваннарда миенең һәм арка миенең шешүе) авыруын тикшерү нәтиҗәсендә, бу авыруны хлоридлар сыекчасы белән дәвалау методы эшләнде. Бу метод хәзерге көндә бөтен Советлар Союзында кулланыла һәм яхшы нәтиҗәләр бирә. Авыл хуҗалыгы фәннәре буенча Бөтенсоюз Академиясенең XV нче пленумы бу методны яхшы дип тапты.

1939 нчы елда терлекләрне энцефаломиэлит авыруыннан саклау чараларының методы эшләнде. Бу метод СССР Наркомземы тарафыннан расланып, практикага кертелде.

Институт, шулай ук, яш терлекләрдә була торган аш казаны-эчәге авыруларын өйрәнде, терлекләрне мондый авырулардан саклау һәм дәвалау өчен „Ацидофилин“ дигән дару хәзерләү юлын күрсәтте.

Түләмә (Сибирская язва) микроблары белән зарарланган тиреләргә, аппаратларга һәм башкаларга дезинфекция ясау, шулай ук рожа белән зарарланган дуңгыз тиреләренә дезинфекция ясау методлары эшләнде. Бу методлар барсы да түләмә авыруына каршы көрәш чаралары турындагы инструкциягә кертелделәр.

Терлекләрнең суалчан (глист) авыруы белән авырулары терлекчелек эшенә бик зур зарар китерә. Бу авыру терлекләрнең продукт бирүләрен киметә, аларны ябыктыра һәм төрле йогышлы авырулар белән авыруларына сәбәп була. Мондый терлекләрнең итләрен ашаудан кешеләргә дә авыру йогуы мөмкин. Хәзерге көнне институт бу авыруның Татарстанда ничек таралганлыгын һәм аны дәвалау методларын өйрәнә. Шуның аркасында суалчан авыруына каршы планлы чараларны үткәрергә мөмкин булачак. Институт шулай ук умарта кортларының авыруларын дәвалау буенча да күп кенә чаралар эшләде.

1938—1939 нчы елларда институт, атларда була торган йогышлы анемия (кан азлык) авыруын тикшерү һәм аны бетерү буенча зур эш башкарды.

Йогышлы авыруларга каршы көрәшне оештыру өчен институт районнарга экспедицияләр һәм үзенең фәнни работникларын җибәрә. Алар терлекләрнең йогышлы авыруларын тикшерәләр һәм аларны бетерү чараларын үткәрәләр. Институт терлекләрдә була торган йогышлы авыруларга каршы көрәш буенча район работникларына һәм Татарстан Наркомземына консультацияләр бирә. Бер үк вакытта ветеринария врачларының белемен күтәрү өстендә эшли.

Ветеринария эшендә зур гына җитешсезлекләр дә бар әле. Шушы көнгә кадәр Татарстанның 12—15 ләп районында ветеринария врачлары юк. 20—25 ләп районда тик берәр генә өлкән ветврачлар эшли. Кайбер районнарда гына икешәр ветврач бар. Күп кенә районнарда терлекләрне авырулардан саклау һәм дәвалау эшләре ветфельдшерларга йөкләнгән. Татарстанның ветеринария эшендә теория белән практика арасында өзеклек сизелә. Күп кенә бай фәнни материал көтепханәләрдә генә саклана, практикага кертелми. Мәсәлән, безнең тарафтан эшләнгән „Ацидофилин“ даруы терлекләрне авырудан саклау һәм дәвалау өчен практикада бик сирәк кулланыла. Бу җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерергә кирәк.

А. Сергеев.
Казан Фәнни-Тикшеренү Ветеринария институты директоры.

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 1324
ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА. ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД.
ЗАКАЗ № 1194.